ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 43 от «31» 01 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 374 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 374 нче карары (алаг таба – Карар) белән расланган Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына (чит ил гражданнарына) бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бер мәртәбә бирелә торган түләү күләме

2.1. Контракт төзегән Россия Федерациясе гражданинына (чит ил гражданинына) контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разряд), Казан шәһәре (алга таба - контрактчы) аша бер тапкыр бирелә торган түләү, аерым затлар контракт төзүдә ярдәм итмәсә, 200 000 (ике йөз мең) сум күләмендә бирелә. 2.2. Контрактчыга контракт төзүдә аерым затлар ярдәм иткән очракта, бер тапкыр бирелә торган түләү 100 000 (йөз мең) сум күләмендә бирелә».

2. Әлеге карарның көче 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Ефимовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гарипов

0000012555